**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Түбән Биш авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 125** **«28» март 2024 ел**

**Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 нче декабрендәге 151 нче номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы Уставына таянып

КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 нче декабрендәге 151 нче номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 35 нче пунктның 12 нче абзацында "тимер юл юллары" дигән сүзләрне алып атырга;

1.2. 37 нче пунктның алтынчы абзацында "һәм тимер юл" сүзләрен алып атырга;

1.3. 66 нчы пунктта "(тимер юл)" сүзен алып атырга;

1.4. 67 нче пунктта "тимер юл" сүзен алып атырга;

1.5. 68 нче пунктта "тимер юл" сүзен алып атырга;

1.6. 108 нче пунктның алтынчы абзацында «тимер юл кичүләре янында» дигән сүзләрне алып атырга;

1.7. 183 нче пунктның икенче абзацында «терлекчелек продуктлары» дигән сүзләрне «хайваннардан алынган продукция» дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), торак пунктлар территориясендә махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе Д.В.Насертдинов